ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

**Гражданнар тарафыннан бакчачылык, яшелчәчелек яисә дача хуҗалыгы алып бару өчен төзелгән коммерциячел булмаган оешмаларның әлеге оешмаларны хуҗалык-көнкүреш өчен су белән тәэмин итү максатларында, җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия алмыйча, җир асты суларын чыгару хокукы срогын озайту мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе В.В. Володинга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгате турында**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе В.В. Володинга гражданнар тарафыннан бакчачылык, яшелчәчелек яисә дача хуҗалыгы алып бару өчен төзелгән коммерциячел булмаган оешмаларның әлеге оешмаларны хуҗалык-көнкүреш өчен су белән тәэмин итү максатларында, җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия алмыйча, җир асты суларын чыгару хокукы срогын озайту мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгатен кабул итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе В.В. Володинга җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының әлеге мөрәҗәгатен хуплауны сорап, Россия Федерациясе субъектларының закон чыгару (вәкиллекле) органнарына мөрәҗәгать итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2019 елның 11 июле
№ 2985-V ДС